Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XI-1**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 15 июле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 88, 89, 90 маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-1 номерлы карары белән кабул ителгән район Уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 6 маддәнең 1 өлешендә:

а) 16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16) район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), чыгару (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 24.1 пунктны өстәргә:

«24.1) район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрене) саклап калу, алардан файдалану һәм аларны популярлаштыру, район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрене) саклау;»;

в) 31 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31) район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;»;

2) 7 маддәнең 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру».»;

3) 8маддәдә:

а) аталышын (исемен) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8маддә. Районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләре булып торучы һәм районның авыл җирлекләре территорияләрендә район җирле үзидарә органнары хәл итә торган башка мәсьәләләр»;

б) 1 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) район составына керүче авыл җирлекләре чикләрендә (алга таба - авыл җирлекләре), Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне оештыру;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын, юл хәрәкәтен оештыру буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыр;»;

6,11 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

4) 17 маддәнең 3 өлешендәге 4 пунктына түбәндәге сүзләрне өстәргә: «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 маддәсендә каралган очраклардан тыш;

5) 20 маддәнең 4 өлешендә «билгеләнә» сүзеннән соң «әлеге Устав һәм» сүзләрен өстәргә;

6) 24 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. Район Советы юридик зат хокукларына ия.»;

7) 25 маддәнең 1 өлешендә «56» санын «54» санына алмаштырырга;

8) 27 маддәдә:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Район Советы депутатының вәкаләтләре чоры икедән ким һәм биш елдан артык була алмый..;

б) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Район Советы депутаты 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ санлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белен билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны (бурычлар, йөкләмәләрне) башкарырга тиеш. Район Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла шул очракта, әгәр чикләүләр, тыюлар, бурыч-йөкләмәләр үтәлмәсә, ә алар 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән, әгәр “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.»;

в) 6 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мәнфәгатьләр каршылыгы (район Советы депутатының шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки читләтеп) депутат вәкаләтләренең тиешле, объектив һәм гадел гамәлгә ашырылуына тәэсир итә яки йогынты ясый ала торган ситуацияләр) барлыкка килү куркынычы булганда, район Советы билгеләгән тәртиптә, бу хакта аңа билгеле булуга ук мәнфәгатьләр конфликты (каршылыгы, низагы) турында яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә, район Советының әлеге мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында карарын үтәргә бурычлы;;»

г) 7 өлешнең 1 пунктында «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре» сүзләрен өстәргә;

д) 8 өлешнең беренче абзацында:

«район Советы» сүзләреннән соң «, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы» сүзләрен өстәргә;

«гражданнар» сүзләреннән соң «, административ» сүзен өстәргә;

36 маддәнең 2 өлешендә «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыра торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

37 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.Район башлыгы район Советы тарафыннан сайлана һәм аның хәлиткеч тавыш хокукына ия рәисе вәкаләтләрен башкара.»;

11а) 39 маддәдә: а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район Башлыгы үз вәкаләтләрен район Советы исеменнән районның яше буенча иң өлкән депутаты тарафыннан имзаланучы вакытлы хезмәт шартнамәсе шартларында даими нигездә гамәлгә ашыра.

Район Башлыгының вәкаләтләре чоры ике елдан да ким һәм биш елдан артыграк була алмый.»;

б) 4 өлешнең 1 пунктында «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре» сүзләрен өстәргә;

в) 4 өлешнең бишенче абзацында «граждан» сүзләреннән соң «, административ» сүзен өстәргә;

г) 5 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Район Башлыгы 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ санлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белен билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны (бурычлар, йөкләмәләрне) башкарырга тиеш. Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла шул очракта, әгәр чикләүләр, тыюлар, бурыч-йөкләмәләр үтәлмәсә, ә алар 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы тору турында” 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс

инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән, әгәр “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы каралмаган булса.»;

12) 40 маддәнең 1 өлешендәге 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4)үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгара;»;

13) 42 маддәдә:

а) 4 өлештә:

«азат ителгән нигездә» сүзләрен «үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

Район Башлыгы урынбасарының вәкаләтләр чоры икедән ким һәм биш елдан артык була алмый.»;

б) 8 өлештә:

беренче абзацта «эшли торган» сүзен «үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән» сүзләреннән соң «, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләре» сүзләрен өстәргә;

3 пунктның беренче абзацында «граждан» сүзләреннән соң «, административ» сүзен өстәргә;

в) 9 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Район Башлыгы урынбасары “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны (йөкләмә-вазыйфаларны) башкарырга тиеш. Район Башлыгы урынбасарының вәкаләтләре вакытыннан алда чикләүләр, тыюлар, бурычларны үтәмәгән очракта туктатыла, ә алар 2008 елнып 25 декабрендеге “Коррупцияге каршы тору турында” гы 273-ФЗ номерлы Федераль закон, 2012 елның 3 декабрендәге “Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында” 230-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 7 маендагы “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 79-ФЗ номерлы Федераль законнарда тәгаенләнгән.».»;

14)46 маддәдә:

а) 1 өлештә:

3 пунктның өченче абзацында «резервлау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- район территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерып җыю), чыгару (ташу), эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

5 пунктта түбәндәге эчтәлекле тугызынчы абзац өстәргә:

«-район милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклауны, алардан файдалануны һәм аларны популярлаштыруны, район территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклауны тәэмин итә;»;

5 пунктта тугызынчы - ундүртенче абзацларны унынчы - унбишенче абзацлар дип санарга;

5 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- район территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, районның рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын уздыруны оештыра;»;

6 пунктның тугызынчы абзацында «, муниципаль хезмәт өчен кадрлар әзерләүне мәгариф турында Россия Федерациясе законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә оештыра» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра.»;

в)3 өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Башкарма комитет районның авыл җирлекләре территорияләрендә районның җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) авыл җирлекләре чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны электр, җылылык һәм газ белән тәэмин итүне оештыра;»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларда машина кую урыннарын (парковка урыннарын) төзүне һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итүне дә кертеп, юл хәрәкәте куркынычсызлыгын тәэмин итә, авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын муниципаль тикшереп торуны гамәлгә ашыра, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Россия Федерациясе законнары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.;»;

6,11 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

16 пунктта «җирләрне резервлау һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

50 маддәнең 1 өлешендәге 9 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9)үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгара;»;

52 маддәнең 4 өлешендә «Җитәкче» сүзен төшереп калдырырга;

54 маддәнең 5 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Районның контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасын биләүгә бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

Районның контроль-хисап палатасы рәисе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре әлеге Устав тарафыннан федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнә.»;

18)56 маддәдә:

а) 1 өлештә:

түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:

«-муниципаль ихтыяҗлар өчен муниципаль район чикләрендә җир кишәрлекләрен резервлый.»;

сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга;

б) 2 өлештә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«районның Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы районның авыл җирлекләре территорияләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:»;

түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«- авыл җирлекләре чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җирләрне резервлауны гамәлгә ашыра;»;

икенче-өченче абзацларны өченче - дүртенче абзацлар дип санарга;

19) 61 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«61 маддә. Район Башлыгы һәм аның урынбасары, район Советы депутатлары, район Контроль-хисап палатасы рәисе, башка вазыйфаи затлар эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре

1. Район Башлыгына һәм аның урынбасарына, район Советы депутатларына, районның Контроль-хисап палатасы рәисенә, башка вазыйфаи затларга бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, әлеге Устав һәм район Советы карарлары белән билгеләнә.

2. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затка гарантияләнә:

1) муниципаль хокукый актлар нигезендә вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итә торган эш шартлары;

2) милек рәвешләренә бәйсез рәвештә җирле үзидарә органнарының, җирле бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тулысынча яисә өлешчә финанслана торган яки салымнар һәм мәҗбүри түләүләр буенча ташламаларга ия, яисә җирле үзидарә органнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә куелган һәм район территориясендә урнашкан органнар буларак законнар нигезендә предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта кабул итүгә хокук;

3) районның җирле үзидарә органнары кабул иткән хокукый актларга тоткарлыксыз керү хокукы;

4) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм материалларны муниципаль хокукый актларда билгеләнгән

тәртиптә районның тиешле территориясендә урнашкан җирле үзидарә органнарыннан, ә федераль законнарда каралган очракларда - барлык милек рәвешләрендәге оешмалардан, иҗтимагый берләшмәләрдән һәм аларның вазыйфаи затларыннан алу хокукы;

5) акчалата хак түләүне үз вакытында һәм тулы күләмдә алуга хокук;

6) эш (хезмәт) вакытының нормаль дәвамлылыгын билгеләү, ял көннәре һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәре бирү белән тәэмин ителә торган ял, шулай ук еллык түләүле төп һәм өстәмә отпусклар;

7) муниципаль вазыйфаны биләүче затка һәм аның гаилә әгъзаларына медицина хезмәте күрсәтү, шул исәптән муниципаль вазыйфа биләүче зат пенсиягә чыккач та;

8) муниципаль вазыйфа зат тарафыннан биләгән чорда яисә ул туктатылганнан соң авыру очрагына яисә хезмәткә сәләтне югалткан очракта мәҗбүри дәүләт социаль иминләштерүе, вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә килеп чыккан очракта;

9) пенсия белән тәэмин итү “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында” 2009 елның 12 февралендәге 15-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче зат гаилә әгъзаларын, аның федераль законнар нигезендә вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә килеп чыккан үлеме очрагында пенсия белән тәэмин итү;

10) муниципаль вазыйфаны биләүче затны һәм аның гаилә әгъзаларын түбәндәге очракларда, тәртиптә һәм шартларда аларның вазыйфаи вәкаләтләрен үтәүгә бәйле рәвештә көч кулланудан, янаулардан һәм башка хокукый булмаган гамәлләрдән федераль законнарда һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә яклау;

11) хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау;

12) үз вәкаләтләрен башкарганда транспорт хезмәте күрсәтү, шулай ук хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен биләгән вазыйфага бәйле рәвештә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә компенсация.

3. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затка әлеге маддәнең 2 өлешендәге 1 - 4 һәм 10 пунктларында каралган гарантияләр бирелә, муниципаль вазыйфаны биләүгә бәйле чыгымнарны компенсацияләү гарантияләнә, шул исәптән муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфа биләүгә бәйле рәвештә хезмәт командировкалары белән бәйле чыгымнарны, шулай ук дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек Уставында билгеләнә торган чорга эш (вазыйфа) урынын саклап калу, ул тулаем алганда аена икедән ким һәм алты эш көненнән артык була алмый.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре җирле бюджет акчалары исәбеннән финанслана.

20) 67 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5.Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеген гамәлгә ашыруны нигезсез кыенлаштыра торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында, Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары уздыра торган экспертиза үткәрелергә мөмкин.»;

21)69 маддәнең 1 өлешендәге 3 пунктында «Җитәкче» сүзен төшереп калдырырга;

22)70 маддәдә:

а)2 өлештә «район Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен «районның Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

б)түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычлар билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар проектлары Татарстан Республикасы законы нигезендә муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары (җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары) үткәрә торган җайга салу йогынтысын бәяләү үткәрелергә мөмкин, район Советының җирле салымнарны һәм җыемнарны, шулай ук бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлары проектларын билгеләүче, үзгәртүче, туктатып торучы, юкка чыгаручы норматив хокукый актлары проектларыннан гайре.

Эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен яңа бурычларны билгели торган яисә муниципаль норматив хокукый актларда элек каралган бурычларны үзгәртә торган муниципаль хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык бурычлар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм район бюджетының нигезләнмәгән чыгымнарын барлыкка китерүче нигезләмәләрне ачыклау максатларында уздырыла..»;

23)71 маддәгә түбәндәге эчтәлекле 3.1 өлеш өстәргә:

«3.1. Район башлыгы район Советы карарларын кабул иткәндә район Советы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»;

24)72 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«72 маддә. Район Башлыгының хокукый актлары

1. Район Башлыгы законнар, әлеге Устав һәм район Советы карарлары белән билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, шулай ук “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар нигезендә әлеге Устав белән аның компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча да.»;

25) 73 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«73 маддә. Район Башкарма комитетының хокукый актлары

1. Район Башкарма комитеты җитәкчесе федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, әлеге Уставта, район Советы карарларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә район башкарма комитетының җирле әһәмияттәге мәсьәләләре һәм районның җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләре буенча карарлар, шулай ук Башкарма комитетның район Башкарма комитетының эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләрен чыгара»;

26) 74 маддәдә:

а)1 өлешнең өченче абзацында «үзгәрешләр кертү» сүзләрен «үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү» сүзләренә алмаштырырга;

б)2 өлештә «Җитәкче» сүзен төшереп калдырырга;

в)5 өлештә «район Башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләрен «районның Башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга;

г)8 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) муниципаль хокукый акт реквизитлары күрсәтелә.

Муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә хокукый акт текстын урнаштыру (бастырып чыгару) : http://pravo.tatarstan.ru;

-хокукый акт текстын районның җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган басма массакүләм мәгълүмат чараларында йә район территориясендә таратыла торган һәм район Советы карары белән билгеләнгән башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый акт текстын башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы турында тамга булырга тиеш.

Муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү хокукый акт текстын веб-адрес буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында районның рәсми сайтында урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru.»;

27)81 маддәнең 2 өлешендә «аларны акчалата тотуга чыгымнар» сүзләрен «аларның хезмәте өчен түләү чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

86 маддңең 9 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Район бюджетының үтәлеше турындагы карар белән, район бюджетының керемнәренең, чыгымнарының һәм кытлыгының (артыклыгының) гомуми күләмен күрсәтеп, хисап финанс елында район бюджетының үтәлеше турында хисап раслана.

Хисап финанс елында район бюджетының үтәлеше турында район Советы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча район бюджеты

керемнәре;

район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча район бюджеты чыгымнарын;

бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча район бюджеты чыгымнары;

бюджетлар кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары.

Район бюджетын үтәү турындагы карар белән шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексында һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы законында, район Советының муниципаль хокукый актында район бюджетын үтәү турындагы карар өчен билгеләнгән башка күрсәткечләр раслана..».

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезләмәләренең кушымтада бирелә торган яңа редакциясен расларга.

3. Карар, федераль законнар нигезендә үз көченә керүнең башка срокларына ия булган пунктлардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

4. Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда юстиция органнарына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

5. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң «Авыл офыклары» район газетасында (»Сельские горизонты») бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев